# КАРАР

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселок торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«13» ноябрь 2019 ел № 5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2019 елның 13 ноябрендә узган: «Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселок территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Нариманов исемендәге поселокның торак пункт территориясен төзекләндерү.

2) Нариман авылында чаралар үткәрү" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 10 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 10 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1 Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселок торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2«Сез, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Нариманов исемендәге поселок территориясендә яшәүче I төркем инвалидларыннан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 3500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Нариманов исемендәге поселокның торак пункт территориясен төзекләндерү.

2) Нариман авылында чаралар үткәрү" мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нариманов исемендәге поселокның мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыены рәисе Р.Г. Хисамов

Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов